ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2024ел № 8131

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы Карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницыаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 24 июнендәге 3192 номерлы, 2023 елның 2 июнендәге 4670 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1005 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницыаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - 15 эш көне (әлеге Регламентта каралмаган очракларда – 45 көннән артык түгел). Бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар турында мәгълүматлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булмаганда, гариза бирүчегә торак йортка яки бакча йортына хокук билгеләүче документны яисә мондый документның нотариаль таныкланган күчермәсен тапшыру кирәклеге турында белдерү җибәрелгән очракта – 20 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән исәпләнә башлый.

Гариза бирүчегә консультация бирү срогы, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнардан ведомствоара запроска җавап көтү срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 2.17 пункт өстәргә:

«Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан

билгеләнгән таләпләр нигезендә, мәгълүмати технологияләрдән файдаланып муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыру (машинада укыла торган тасвирлама) гамәлгә ашырылмый.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов